**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

10 ноябрь 2022 ел Яңа п. № 2

Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 21 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылында яшәү урыны буенча Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Чернобыль атом электростанциясендә аварияне ликвидацияләүчеләр-чернобыльчеләр, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

- су челтәрләрен проектлау;
- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру

«ӘЙЕ» «ЮК».

3.Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә,

4. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Яңа Сарайлы авылы, Үзәк ур., 51А.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

8. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы М.Г. Фазылҗанов